КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 29 сентябрь г.Казань № 779

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 27 май, 368 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне савыктыру өлешендә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибен камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибен раслау турында» 2024 ел, 27 май, 368 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 15 октябрь, 884 нче; 2025 ел, 12 май, 318 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гаризада һәм документларда (документлар күчермәләрендә), мәгълүматларда каршылыклы яки туры килми торган урыннар булу.»;

3.4 пунктта:

өченче абзацка «(оешма хезмәткәрләренең саны яки штаты кыскаруга, яисә оешма ябылуга, яисә федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә бирелгән медицина бәяләмәсе нигезендә хезмәткәрне хезмәт эшчәнлегенә тулысынча сәләтсез дип тануга, яисә эш бирүчедә хезмәткәр өчен медицина бәяләмәсе нигезендә кирәк булган тиешле эш булмауга бәйле рәвештә, эштән азат итүдән тыш)» сүзләрен өстәргә;

бишенче һәм алтынчы абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Хезмәткәргә бирелгән Сертификат территориаль социаль яклау органы тарафыннан Сертификатны алган хезмәткәр эштән азат ителү турында хәбәрнамә алынган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча яки әлеге пунктның икенче һәм дүртенче абзацларында каралган башка хәлләр килеп чыгу турында мәгълүмат кергән көннән алып гамәлдән чыгарыла.»;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Сертификат хуҗасы түбәндәгеләргә бурычлы:

эштән азат ителгән очракта, эштән азат ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган ике эш көне эчендә территориаль социаль яклау органына үзенең эштән азат ителү факты һәм нигезе турында хәбәр итәргә;

Сертификатны әлеге Тәртипнең 3.4 пунктындагы өченче абзацында каралмаган нигезләр буенча эштән азат ителгәннән соң файдаланган очракта, Сертификатның бәясен әлеге Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә шифиханә-курорт оешмасының шифаханә-курорт дәвалануына юллама бәясен түләү (өлешчә түләү) өчен Сертификат бирелгән көннән алып 30 эш көне чыкканга кадәр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарырга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин